| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 132**

«2018-2020 елларда Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
муниципаль милке белән идарә итү»
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 20 декабрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү» муниципаль программасын әлеге механизмга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
10.02.2020 елның 132 номерлы
карарына
кушымта

**Муниципаль программа**
**Паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018 – 2020 елларда Татарстан республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү» (алга таба – Программа) |
| Муниципаль Программаның заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчесе | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| Программаның максаты: | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемлелеген һәм сакланышын тәэмин итү. |
| Программаның бурычлары | 1. Билгеләнгән тәртиптә мөлкәт, шул исәптән муниципаль милектәге җир ресурсларына ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү.<br>2. Муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Программаны финанслауның еллар буенча һәм чыганакларга бүленгән күләме | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 6 786,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2018 елда – 2 753,1 мең сум;<br>2019 елда – 2 619,7 мең сум;<br>2020 елда – 1 414,0 мең сум.<br>Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар суммасы чираттагы финанс елына Кукмара район Советы карары нигезендә ел саен ачыкланачак.<br>Программаны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар суммасы финанс елы дәвамында үзгәрергә мөмкин. |
| Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | - җирле бюджетның керем өлешен тулыландыру;<br>- салым булмаган керемнәрнең рациональ администрациясе;<br>- муниципаль милекне исәпкә алуны оптимальләштерү;<br>- мөлкәт һәм җир кишәрлекләрен арендалаган өчен бурыч алу |

| | |
|---|---|
| | буенча претензия-дәгъва эшен арттыру;<br>- муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә бюджетның салым булмаган керемнәрен арттыру (аукцион сатулары аша сату). |

## 1. Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы

Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү гамәлгә ашырыла.

Җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлекләрен арендага, милеккә, түләүсез сроклы файдалануга, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карарлар кабул ителә, җир кишәрлекләренә ия булу яки алардан файдалану хокукларын күчерүне күздә тоткан аренда, түләүсез сроклы файдалану, сату-алу шартнамәләре төзелә. Югарыда күрсәтелгән шартнамәләрне төзү тәртибе үзенчәлекләре Россия Федерациясе Җир кодексы белән билгеләнә.

2016 елның узган чорында Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан 294,9 га мәйданлы 598 җир кишәрлеге бирелгән, шул исәптән:

- гомуми мәйданы 240,7 га булган 287 җир кишәрлеге арендага бирелде;
- гомуми мәйданы 48,5 га булган 300 җир кишәрлеге милеккә;
- гомуми мәйданы 5,7 га булган 11 җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга тапшырылды.

Арендага бирелгән 287 җир кишәрлегеннән:

- гомуми мәйданы 37,7 га булган 249 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы нигезендә шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелде;
- гомуми мәйданы 8,3 га булган 8 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары нигезендә эшкуарлык максатлары өчен бирелде,
- гомуми мәйданы 194,7 га мәйданлы 30 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясы һәм «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль закон нигезендә авыл хуҗалыгы производствосы өчен бирелде.

Милеккә бирелгән 300 җир кишәрлегеннән:

- гомуми мәйданы 27,1 га булган 176 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20, 39.18, 39.3 статьялары һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль закон нигезендә индивидуаль торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелде;
-гомуми мәйданы 8,1 га булган 8 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясы һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын

гамәлгә кертү турында» Федераль закон нигезендә эшмәкәрлек максатлары өчен бирелде;

- гомуми мәйданы 0,3 га булган 7 җир кишәрлеге Дини оешмаларга Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә милек итеп бирелде;

- гомуми мәйданы 13 га булган 109 җир кишәрлеге Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы нигезендә 2016 елда күп балалы гаилә әгъзаларына шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гомуми өлешле милеккә бирелде.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы эшли башлаганнан бирле Кукмара муниципаль районында күп балалы гаиләләргә шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гомуми мәйданы 110,1 га булган 918 җир кишәрлегә бирелгән.

## 2. Программаның максатлары, бурычлары

Әлеге Программаның максаты – муниципаль милек белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген тәэмин итү.

Программаның бурычлары:

- билгеләнгән тәртиптә мөлкәт, шул исәптән муниципаль милектәге җир ресурсларына ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү.

- муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен нәтиҗәле эш итү һәм алардан файдалануны тәэмин итү.

## 3. Бюджет ассигнованиеләре турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 6 786,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2018 елда – 2 753,1 мең сум;

2019 елда – 2 619,7 мең сум;

2020 елда – 1 414,0 мең сум.

Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар суммасы чираттагы финанс елына Кукмара район Советы карары нигезендә ел саен ачыкланачак.

Программаны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар суммасы финанс елы дәвамында үзгәрергә мөмкин.

## 4. Программаның төп көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирламасы

Программа чараларын гамәлгә ашырудан турыдан-туры икътисади нәтиҗә:

- җирле бюджетның керем өлешен тулыландыру;
- салым булмаган керемнәрнең рациональ администрациясе;
- муниципаль милекне исәпкә алуны оптимальләштерү;
- мөлкәт һәм җир кишәрлекләрен арендага бирү буенча бурычларны түләтү буенча претензия-дәгъва эшен көчәйтү;
- муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә бюджетның салым булмаган керемнәрен арттыру (аукцион сатулары аша мөлкәтне сату).

ФИНАНС-ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ

| Чара исеме | Башкаручы | Финанслау чыганагы | Программаны тормышка ашыру өчен акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | БАРЛЫГЫ | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү» | | | | | | |
| Хезмәткәр хезмәтенә түләү | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Муниципаль бюджет | 3495,4 | 1243,7 | 1252,7 | 999,0 |
| Хезмәт өчен түләү хисаплау | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Муниципаль бюджет | 1017,3 | 370,4 | 344,9 | 302,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен башка товарлар, эшләр һәм хезмәт сатып алу | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Муниципаль бюджет | 2274,1 | 1139,0 | 1022,1 | 113,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **6786,8** | **2753,1** | **2619,7** | **1414,0** |